ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОЛЫ МЕМИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.12.2017 с. Большие Меми 25

Депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен бирелә торган урыннар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2004 елның 19 июнендәге «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 54-ФЗ номерлы Федераль законнар, Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Олы Меми авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бирелгән урыннарны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә билгеләргә.
2. Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Олы Меми авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналарның исемлеген әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә.
3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән биналарны бирү тәртибен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә билгеләргә.
4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина

Олы Меми авыл җирлеге
Башкарма комитетының
11.12.2017 ел № 25 карарына
1 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Олы Меми авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен махсус бүлеп бирелгән урыннар

1. Олы Меми авылы, Үзәк урамы-үзәк мәйдан кибет яныңдагы территория

2. Заборная Поляна авылы, Үзәк урамы, мәйданчык, 1нче һәм 2нче йорт янында

Олы Меми авыл җирлеге
Башкарма комитетының
11.12.2017 ел № 25карарына
2 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Олы Меми авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен бирелә торган бүлмәләр исемлеге

| т/б | Адресы | Баланстотучы |
|---|---|---|
| | Олы Меми авылы, Молодежная урамы, 19 йорт-авыл мәдәният йорты | Олы Меми авыл җирлеге башкарма комитеты |

Олы Меми авыл җирлеге
Башкарма комитетының
11.12.2017 ел № 25
карарына

1 нче кушымта

Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Олы Меми авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен биналар бирү тәртибе

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә сайлаучылар белән очрашулар уздыру өчен урыннар бирү шартларын билгели.

2. Олы Меми авыл җирлеге башкарма комитеты Россия Федерациясе Дәүләт Думасы депутатларының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының, Югары Ослан муниципаль районы Советы депутатларының, Олы Меми авыл җирлеге Советы депутатларының сайлаучылар белән очрашуларын уздыру өчен бирелә торган биналарның исемлеген билгели.

3. Әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән биналар түләүсез нигездә бирелә.

4. Депутатлар бинаны бирү өчен, сайлаучылар белән очрашу уздыру өчен, оешма җитәкчесе, учреждение, балансында бина урнашкан предприятие адресына бина бирү турында гариза җибәрә.

5. Гаризада чараны уздыру датасы, вакыты, дәвамлылыгы, катнашучыларның якынча саны, заявканы бирү датасы, чараны уздыру өчен җаваплы күрсәткечләр, аның контактлы телефоны күрсәтелә.

6. Бүлмәне бүлеп бирү турында гариза гариза гариза биргән көннән алып өч көн эчендә оешма, учреждение, предприятие җитәкчесе тарафыннан карала.

7. Биналар эш көннәрендә бу эш процессына комачауламау шарты белән бирелә. Ял (бәйрәм) көннәрендә бина оешма, учреждение, предприятиеләр җитәкчеләре белән килештереп бирелә.